**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О профилактике правонарушений в Республике Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 декабря 2016 года

## Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон принят в соответствии с Федеральным законом от 23 июня 2016 года № 182-ФЗ «Об основах системы профилактики правонарушений в Российской Федерации» (далее – Федеральный закон) и регулирует отдельные общественные отношения, возникающие в сфере профилактики правонарушений на территории Республики Татарстан.

## Статья 2. **Основные термины и понятия**

В настоящем Законе основные термины и понятия используются в том же значении, что и в Федеральном законе.

## Статья 3. **Правовая основа системы профилактики правонарушений**

Правовую основу системы профилактики правонарушений в Республике Татарстан составляют Конституция Российской Федерации, общепризнанные принципы и нормы международного права, федеральные конституционные законы, Федеральный закон, другие федеральные законы и иные нормативные правовые

акты Российской Федерации, Конституция Республики Татарстан, настоящий Закон и иные нормативные правовые акты органов государственной власти Республики Татарстан, муниципальные нормативные правовые акты.

Статья 4. **Принципы профилактики правонарушений**

Профилактика правонарушений на территории Республики Татарстан осуществляется на основе принципов, установленных Федеральным законом.

Статья 5. **Субъекты профилактики правонарушений**

1. Состав субъектов профилактики правонарушений определяется в соответствии с Федеральным законом.

2. Субъекты профилактики правонарушений осуществляют свою деятельность в пределах компетенции, установленной Федеральным законом.

Статья 6. **Полномочия Государственного Совета Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений**

Государственный Совет Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений осуществляет следующие полномочия:

1) осуществляет законодательное регулирование в сфере профилактики правонарушений;

2) осуществляет контроль за исполнением законодательства Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений;

3) утверждает и контролирует исполнение бюджета Республики Татарстан в части расходов на профилактику правонарушений в соответствии с бюджетным законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан;

4) осуществляет иные полномочия в соответствии с законодательством.

Статья 7. **Полномочия Президента Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений**

Президент Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений осуществляет следующие полномочия:

1) принимает нормативные правовые акты в сфере профилактики правонарушений;

2) создает республиканский координационный орган в сфере профилактики правонарушений, утверждает положение о нем и его персональный состав;

3) обеспечивает координацию деятельности органов исполнительной власти Республики Татарстан с иными органами государственной власти Республики Татарстан;

4) в соответствии с законодательством Российской Федерации организовывает взаимодействие органов исполнительной власти Республики Татарстан с федеральными органами исполнительной власти и их территориальными органами, органами местного самоуправления;

5) осуществляет иные полномочия в сфере профилактики правонарушений.

Статья 8. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений**

Кабинет Министров Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений осуществляет следующие полномочия:

1) принимает нормативные правовые акты в сфере профилактики правонарушений;

2) разрабатывает и принимает меры по реализации государственной политики в сфере профилактики правонарушений на территории Республики Татарстан;

3) обеспечивает взаимодействие органов исполнительной власти Республики Татарстан и лиц, участвующих в профилактике правонарушений;

4) обеспечивает осуществление профилактики правонарушений в формах профилактического воздействия, предусмотренных Федеральным законом;

5) осуществляет иные полномочия в сфере профилактики правонарушений.

Статья 9. **Права органов местного самоуправления в сфере профилактики правонарушений**

Органы местного самоуправления в Республике Татарстан в соответствии с полномочиями, установленными Федеральным законом, Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», другими федеральными законами, настоящим Законом и муниципальными правовыми актами, в пределах своей компетенции обладают следующими правами:

1) принимают муниципальные правовые акты в сфере профилактики правонарушений;

2) создают координационные органы в сфере профилактики правонарушений;

3) принимают меры по устранению причин и условий, способствующих совершению правонарушений;

4) обеспечивают взаимодействие лиц, участвующих в профилактике правонарушений на территории муниципального образования;

5) осуществляют профилактику правонарушений в формах профилактического воздействия, предусмотренных Федеральным законом;

6) реализуют иные права в сфере профилактики правонарушений.

Статья 10. **Государственные и муниципальные программы в сфере профилактики правонарушений**

1. Органы государственной власти Республики Татарстан в целях реализации государственной политики в сфере профилактики правонарушений в соответствии с требованиями бюджетного законодательства и законодательства в сфере стратегического планирования разрабатывают государственные программы Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений.

2. Органы местного самоуправления в Республике Татарстан вправе разрабатывать муниципальные программы в сфере профилактики правонарушений.

Статья 11. **Функционирование системы профилактики правонарушений**

1. Функционирование системы профилактики правонарушений осуществляется на основе государственных программ Российской Федерации, государственных программ Республики Татарстан, муниципальных программ в сфере профилактики правонарушений.

2. Финансирование расходов субъектов профилактики правонарушений, связанных с реализацией государственных программ Российской Федерации, государственных программ Республики Татарстан, муниципальных программ в сфере профилактики правонарушений, осуществляется за счет и в пределах средств, выделенных соответствующим субъектам профилактики правонарушений.

Статья 12. **Координационные органы в сфере профилактики правонарушений**

1. В целях обеспечения реализации государственной политики в сфере профилактики правонарушений на территории Республики Татарстан, а также в целях координации деятельности в указанной сфере создается Правительственная

комиссия Республики Татарстан по профилактике правонарушений (далее – Правительственная комиссия).

2. Правительственная комиссия является постоянно действующим республиканским координационным органом в сфере профилактики правонарушений.

3. Положение о Правительственной комиссии и ее персональный состав утверждаются Президентом Республики Татарстан.

4. В целях обеспечения реализации государственной политики в сфере профилактики правонарушений на территориях соответствующих муниципальных образований, а также в целях координации деятельности в указанной сфере могут создаваться муниципальные координационные органы.

5. В состав координационных органов в сфере профилактики правонарушений могут входить представители органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, а также руководители общественных объединений. В состав координационных органов в сфере профилактики правонарушений при необходимости могут включаться иные лица.

Статья 13. **Информационное обеспечение профилактики правонарушений**

1. В средствах массовой информации, учредителями которых являются территориальные органы федеральных органов исполнительной власти, органы государственной власти Республики Татарстан и органы местного самоуправления, в соответствии с законодательством о средствах массовой информации публикуются материалы о деятельности в сфере профилактики правонарушений.

2. В целях информационного обеспечения профилактики правонарушений, ее публичности и открытости Правительственной комиссией в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» создается и поддерживается сайт Правительственной комиссии, а также в соответствии с законодательством Российской Федерации могут использоваться официальные сайты органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления.

3. Координационные органы в сфере профилактики правонарушений, созданные на территории Республики Татарстан, регулярно информируют население о своей деятельности через средства массовой информации, официальные сайты органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления.

Статья 14. **Признание утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Республики Татарстан**

Со дня вступления в силу настоящего Закона признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 13 октября 2008 года № 105-ЗРТ «О профилактике правонарушений в Республике Татарстан»;

2) статью 9 Закона Республики Татарстан от 24 июля 2014 года № 76-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан»;

3) Закон Республики Татарстан от 26 марта 2016 года № 16-ЗРТ «О внесении изменений в статьи 5 и 9 Закона Республики Татарстан «О профилактике правонарушений в Республике Татарстан».

Статья 15. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
11 января 2017 года
№ 3-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасында**
**хокук бозуларны профилактикалау турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон “Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында” 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә кабул ителде һәм Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә барлыкка килә торган аерым иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Төп терминнар һәм төшенчәләр**

Әлеге Законда төп терминнар һәм төшенчәләр Федераль законда кулланылган мәгънәдә кулланыла.

3 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау системасының хокукый нигезе**

Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау системасының хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары, федераль конституциячел законнар,

Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар тәшкил итә.

4 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау принциплары**

Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау Федераль законда билгеләнгән принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау субъектлары**

1. Хокук бозуларны профилактикалау субъектларының составы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

2. Хокук бозуларны профилактикалау субъектлары үз эшчәнлекләрен Федераль законда билгеләнгән компетенция чикләрендә башкара.

6 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсен законнар белән җайга сала;

2) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары үтәлешен тикшереп тора;

3) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет законнары нигезендә хокук бозуларны профилактикалауга киткән чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен раслый һәм контрольдә тота;

4) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Президенты хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итә;

2) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә республика координацияләү органын төзи, аның турындагы нигезләмәне һәм аның персональ составын раслый;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлеген оештыра;

5) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

8 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итә;

2) Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чараларын эшли һәм куллана;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

4) хокук бозуларны профилактикалауны Федераль законда каралган профилактик йогынты ясау рәвешләрендә гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

5) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

9 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә җирле үзидарә органнары хокуклары**

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары Федераль законда, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, башка

федераль законнарда, әлеге Законда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәге хокукларга ия:

1) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итә;

2) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координацияләү органнарын төзи;

3) хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү чараларын күрә;

4) муниципаль берәмлек территориясендә хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

5) Федераль законда каралган профилактик йогынты ясау рәвешләрендә хокук бозуларны профилактикалауны гамәлгә ашыра;

6) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка хокукларны гамәлгә ашыра.

10 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт программалары һәм муниципаль программалар**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында бюджет законнары һәм стратегик планлаштыру өлкәсендәге законнар таләпләре нигезендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшли.

2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль программалар эшләргә хокуклы.

11 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау системасы эше**

1. Хокук бозуларны профилактикалау системасы эшчәнлеге хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт программалары, Татарстан Республикасы дәүләт программалары, муниципаль программалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Хокук бозуларны профилактикалау субъектларының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт программаларын, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, муниципаль программаларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарын финанслау хокук бозуларны

профилактикалауның тиешле субъектларына бирелгән акчалар исәбеннән һәм шулар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

12 статья. **Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координацияләү органнары**

1. Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шулай ук әлеге өлкәдә эшчәнлекне координацияләү максатларында хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе (алга таба – Хөкүмәт комиссиясе) төзелә.

2. Хөкүмәт комиссиясе хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә даими эшләүче республика координацияләү органы булып тора.

3. Хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмә һәм аның персональ составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4. Тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шулай ук әлеге өлкәдә эшчәнлекне координацияләү максатларында муниципаль координацияләү органнары төзелергә мөмкин.

5. Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координацияләү органнары составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләре, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре дә керә ала. Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координацияләү органнары составына, кирәк булган очракта, башка затлар да кертелергә мөмкин.

13 статья. **Хокук бозуларны профилактикалауны мәгълүмати тәэмин итү**

1. Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган массакүләм мәгълүмат чараларында массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законнар нигезендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлек турында материаллар бастырып чыгарыла.

2. Хокук бозуларны профилактикалауны мәгълүмати тәэмин итү, аның гавами һәм ачык булуына ирешү максатларында Хөкүмәт комиссиясе тарафыннан “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Хөкүмәт комиссиясе сайты булдырыла һәм аның эшчәнлеге тәэмин ителә, шулай ук Россия Федерациясе

законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының рәсми сайтлары файдаланылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы территориясендә төзелгән хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координацияләү органнары халыкка үз эшчәнлекләре турында даими рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының рәсми сайтлары аша мәгълүмат бирә.

14 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип таныргa:

1) “Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында” 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын;

2) “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясын;

3) “Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында” Татарстан Республикасы законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 26 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын.

15 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 11 гыйнвар
№ 3-ТРЗ